# *«Баланың шәхес булып формалашуында туган телнең роле» ата- аналар өчен консультация*

**Бакчабыздагы тәрбиячеләр эти-әниләр белән һәрвакыт аралашып яшиләр. Ата-ана җыелшлары, әңгәмәләр, консультацияләр һәрдаим булып тора. Балалар белән ничек итеп туган телдә уеннар уйнарга, нинди әйберләр өйрәнергә, баланы ничек кызыксындырырга кирәклеге турында сөйләшәбез, киңәшләр бирәбез. Башлангыч укытучылары белән хәзердә үк нәрсәләргә басым ясарга, ничек итеп мәктәпкә әзерләргә кирәклеге турында педкиңәшмәләрдә ачыклык кертәбез. Бу мәктәпләр өчен дә, безнең өчен дә бик файдалы.**














